ДҮРТ АЯКЛЫ ДУСЛАРГА

«Кәүсәр» эт-мәчеләр өчен татарча «Вискас» тәкъдим итә

> 2

АЛЕКСАНДР ЛАТЫШЕВ

«Республика Татарстан» газетасының үткәне һәм бүгенгесе турында

> 3

ТАМАШАЧЫ МӘХӘББӘТЕ

Җырчы-артистларга халык хөрмәте чәчәк белән генә үлчәнми

> 4



КЕМ КИЛЕР?

«Ак барс» хоккей клубы баш тренерсыз калды

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 52 (28825) | Чәршәмбе | 13 апрель | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

БАТЫРЛЫККА СОКЛАНУ

КАЗАНДА РОССИЯ ГЕРОЕ ДАМИР ИСЛАМОВ ИСТӘЛЕГЕНӘ МУРАЛ ПӘЙДА БУЛДЫ

Хәтер

«Фотосурәткә караганда да матуррак килеп чыкты бугай», – ди граффити рәссамы Азат Алеев, горурлык катыш елмаеп. Шушы көннәрдә ул башкаладагы бер йорт диварына Украинадагы махсус операциядә хәрби бурычын үтәгәндә һәлак булган Россия Герое Дамир Исламовның рәсемен ясады. Батырлыкка сокланып башкарылган иҗат эше хәзер Азатка гына түгел, шәһәр халкына да горурланып карарлык урын булып торачак.

Истәлеккә калсын

Хәрбинең истәлегенә мурал ясау тәкъдимен Азат Алеевка Казанның мәдәният идарәсе һәм танк училищесы җитәкчелеге җиткергән. Кыска гына вакыт эчендә эскизын сызып, эшкә тотынганнар. Асыл егет, ватанның лаеклы улы, батырлык үрнәге итеп күрсәтә алган аны Азат.

– Дамир кебек егетләр башкалар артына ышыкланмый. Алар – гел алгы сызыкта. Минем дә Дамирның нәкъ шул сыйфатын күрсәтәсем килде, – ди бит әнә. Шуның өчен берничә көн тырышкан да. Һава торышы да Азатка кояш кына бүләк итеп торгач, рәсем ясау озакка сузылмаган. Узган атнаның пәнҗешәмбесендә тотынган эшне бу атна башында төгәлләде рәссам.

Рәссам яшерми: муралны әзерләгәндә, хәрбинең каш-күзләренә аеруча зур игътибар бирергә кирәк булган. Кыюлык Дамирның карашында чагылган чөнки. Моны күрсәтми мөмкин түгел.

– Йөзне дөрес, чынбарлыкка якын килерлек итеп ясау аеруча мөһим. Диварны буяганда Дамирны күреп белгән курсантлар килгәләп йөрде. Охшаган, диделәр, – дип ураклаша Азат Алеев.

Азат Алеевның (тәхәллүсе – Sly Dog. – **Авт.**) кем икәнен белмәгәннәр һич югы аның рәсемнәре белән яхшы таныш. Бауман урамындагы «Айфон» тоткан Мона Лизаны, «Тасма» бинасы диварындагы чәчәкләргә су сибүче гүзәл кызны, «Арт Сити» торак комплексындагы Сальвадор Далины, «Чишмәле» скверы янындагы баскычта «Өчпочмаклар белән кыз» рәсемен күргәнегез бардыр инде. Дары заводының 230 еллыгына багышланган мурал да, Казандагы бер йорт диварындагы данлыклы очучы Чкаловка багышланган рәсем дә – Азат эше.

Ул рәсем сәнгатенең граффити төре белән 2010 елдан бирле мавыга. Офис хезмәткәре булып эшләү туйдырганнан соң, күңел кушкан шөгылен кәсепкә әйләндерә. Еш кына акча китерә торган эштән иҗадилык, илһам кача бит. Азат очрагында алай түгел. Рәссамга кулына буяу алыр өчен җим чыгып кына тора. Россия Герое Дамир Исламов батырлыгы да – шуның бер мисалы.

Хезмәттәшләре өчен – батыр хәрби, якыннары өчен – тугры дус һәм иптәш. Дамир Исламовны дуслык кадерен белгән егет буларак искә алалар хәзер.

Хәзерге вакытта Санкт-Петербургта яшәүче Элина Кузнецованы хәрбинең үлеме турында хәбәр тетрәндергән. Ул Дамир Исламов белән бергә балалар бакчасына йөргән, күрше йортларда яшәгәннәр.

Ахыры 2 нче биттә >

kzn.ru

Муралның биеклеге – 10 кат чамасы. Ул Казанның 2 нче хәрби шәһәрчегендәге бер йорт диварында урнашкан.

БЕЛЕШМӘ

Дамир Исламов – Лениногорскида туып-үскән егет. Ул биредә 6 нчы мәктәптә белем алган, соңрак Казан танк училищесын тәмамлаган. Ростов өлкәсендә хәрби хезмәттә була. 25 яшьлек егетнең гомере Украинада махсус операция барышында өзелә. Аның экипажы, дошман белән бәрелешкә кереп, биш танкның дүртесен юк итә. Алга таба һөҗүмгә барганда, Дамирның танкы дошман тубы тиеп шартлый. Экипаж, шул исәптән Татарстан егете дә һәлак була. Аңа үлгәннән соң Россия Герое исеме бирелде.

Хәерле сәгатьтә!

Зәй районында язгы кыр эшләре башланды. «Зәй шикәре», «Зәй» агрофирмалары, «Нива» подразделениесе уҗымнарны минераль ашламалар белән тукландыруга кереште. «Һава торышы әйбәт, җирдә дым күп, югары уңышка өметләнәбез», – диде район хакимияте башлыгы Рәзиф Кәримов.

Район газетасы язганча, быел язгы кыр эшләренә 310 трактор җәлеп ителә. Барлыгы 500 механизатор эшләячәк. Районда язгы кыр эшләрендә әйбәт күрсәткечләргә ирешкән өчен 200–250 механизатор бүләкләнәчәк. Моннан тыш аларның уртача хезмәт хакы 25–47 процентка артачак.

Ятимнәр тораклы булачак

Быел Татарстанда 18 яшькә җиткән 600 ятимне торак белән тәэмин итү күздә тотыла. 48 фатир «Кешеләрне уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» программасы буенча федераль бюджеттан ярдәм хисабына сатып алыначак.

Әлеге дәүләт программасын тормышка ашыруга федераль бюджеттан 56 миллион сум акча килергә тиеш. Моннан тыш республикадан 903,5 миллион сум биреләчәк.

Авылга укытучылар килә

Татарстанда соңгы ике елда «Земский учитель» программасы буенча тәҗрибәле 24 укытучы эшли башлаган. Мәгариф һәм фән министры урынбасары Рамил Хәйруллин белдергәнчә, авыл җирлегендә һәм кечкенә шәһәрләрдә урнашкан мәктәпләргә мөгаллимнәр җитмәү мәсьәләсе өлешчә әнә шул программа буенча хәл ителә.

Быелдан башлап, программа «Заманча мәктәп» федераль проектына кертелгән. Проектта катнашучыларга бер тапкыр 1 миллион сум күләмендә акча бирелә. 2022 елга республикага 10 укытучы өчен квота билгеләнгән. Конкурста катнашырга теләүчеләрдән 15 апрельгә кадәр документлар кабул ителә.

Чир көчәергә мөмкин

Май ахыры – июнь башында илдә коронавирус инфекциясе көчәергә мөмкин. Россия сәламәтлек саклау министры Михаил Мурашко әйтүенчә, яңа дулкынның көче сәламәтлегебезне ни дәрәҗәдә кайгыртуга бәйле булачак. Прививка һәм ревакцинациягә дә, санитария кагыйдәләрен саклауга да кагыла бу. Министр билгеләп үткәнчә, хәзерге вакытта COVID-19 сүлпәнәюгә таба бара, әмма барыбер 200 меңгә якын сырхау медицина оешмалары күзәтүендә әле.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Ришвәтчелеккә – юк!

Кырын эш тынгылык бирми

Татарстанда хокук сакчылары ялган диплом сату белән шөгыльләнгән 50дән артык сайтны фаш иткән. Хәзерге вакытта шуларның тугызы юкка чыгарылган. Әмма, Татарстан мәгариф һәм фән министры урынбасары Рәмис Мөҗипов сүзләренә караганда, сөенергә иртәрәк.

«Алар әкияттәге күпбашлы аждаһа кебек. Бер башын чабып атсаң, аның урынына тагын өчәү үсеп чыга. Без бер сайтны ябуга, артыннан ук яңалары килеп чыга», – дип сөйләде ул журналистлар белән очрашуда. Министр урынбасары сүзләренә караганда, белгечләр БДИ һәм ОГЭ имтиханнары җавапларын сатып ятучы сайтларга да даими күзәтчелек итеп тора.

Мәгариф тармагындагы ришвәтчелек очраклары моның белән генә чикләнми, билгеле. Әйтик, күптән түгел Нурлатның 9 номерлы балалар бакчасында хезмәткәрләрдән акча җыю очраклары ачыкланган. Моннан тыш биредә бакчада бөтенләй эшләмәүче кешеләр исеменә хезмәт хакы һәм премияләр дә күчереп барганнар. Хәзерге вакытта бу факт буенча җинаять эше кузгатылган. «Белем бирү оешмаларында мондый хәлләр күзәтелергә тиеш түгел. Мине барлык җитәкчеләр дә ишетсен иде. Мондый һәр очрак фаш ителәчәк, һәр гаепле зат җаваплылыкка тартылачак», – дип кисәтте Рәмис Мөҗипов.

Күптән түгел Актаныш районының технология техникумында да шундый ук хәл күзәтелгән. 2019 елда биредә фиктив рәвештә 44 студентны укырга алганнар. Бу уку йортына кабул итү планын тутырып, моның өчен акча алу максатыннан эшләнгән. Элегрәк Чүпрәле, Апас районнарындагы уку йортларында да шундый ук алым кулланылганы ачыкланган булган.

Хокук сакчылары Усад бистәсендәге «Айтишка» балалар бакчасында да ике ришвәтчелек очрагына юлыккан. Бакча мөдиренең тормыш иптәше, әти-әнисе белән килене дә биредә эшләгән. Әйтик, аның әтисе биредә 1,5 ставкага урам себерүче булып хезмәт куйган. Чынлыкта исә бу эш, гомумән, башкарылмаган. Хәзерге вакытта бу затларның барысы да эштән куылган.

Кырын эше тотылганнар саны моның белән генә чикләнми, билгеле. Узган ел салым хезмәтеннән керемнәрен яшереп калдырган алты дәүләт хезмәткәрен эштән куганнар. Татарстан Президенты каршындагы коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча идарәнең коррупциягә каршы тикшерүләр бүлеге баш киңәшчесе Салават Рәхимов сүзләренә караганда, 2020 елда республикада ышаныч югалту аркасында шундый өч дәүләт хезмәткәре кәнәфиен бушаткан булган. «Бу саннарның ике тапкыр артуы борчуга сала», – дип белдерде ул журналистлар белән очрашуда.

Чулпан Гарифуллина

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Сүзгә-сүз

Владимир ПУТИН, Россия Президенты:

Бүгенге дөньяда бөтенләй бикләнеп яшәү мөмкин түгел. Россия кебек зур ил өчен бигрәк тә. Шуңа күрә без хезмәттәшлек итәргә теләүчеләр белән бергә эшләүне туктатмаячакбыз.

(«Восточный» космодромына эш сәфәре кысасында әйтелгән сүзләре)

РОССИЯДӘ – ҺӨНӘРЛӘР

«Хоум Кредит» банкы белгечләре оештырган сораштыру нәтиҗәләре күрсәткәнчә, ил халкы иң кызыктыргыч һөнәр итеп IT-тармак белгечен саный икән.



IT-тармак белгече	16%
оешма җитәкчесе, эшкуар	11%
психолог, сәнгать һәм мәдәният вәкиле, дәүләт хезмәтендә эшләүчеләр	8%
туризм, җәмәгать туклануы тармагы хезмәткәрләре	7%

Сөенечле хәбәр!

14 апрельгә кадәр «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» газетасына ташламалы бәядән язылып була!

П2435 җомга саны — Ташламалы бәя **423 сум 48 тиен**

гадәти бәясе – ~~488 сум 10 тиен~~

П2409 атнага дүрт тапкыр чыга — Ташламалы бәя **942 сум 18 тиен**

гадәти бәясе – ~~1099 сум 32 тиен~~

Реклама 16+



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ЛЕНД-ЛИЗ ЯҢАДАН КАЙТА

Россиянең көнбатышында бара торган кискен конфликт үзенең яңа этабына чыкты: НАТО блогы Украинаны яшермичә һәм актив рәвештә коралландыра башлады. «Российская газета» бу хакта «АКШның Оборона министрлыгы Украинаны үзенең яңа коралын сынау өчен файдалана» дигән язма бирде. Көнбатышта да моны яшермиләр: «Украина Switchblade камикадзе-дроннарын сугышта тикшерү өчен полигонга әйләнергә мөмкин», – диләр. Американың Миссисипи штатындагы Билокси шәһәрендә украинлы сугышчылар шундый дроннарны кулланырга өйрәнеп кайтканнар икән. Моннан тыш Пентагон Байден администрациясенең Украинага Россия хәрби аэродромнарына һөҗүм ясарга яраклы корал бирергә әзер булуын хәбәр итте. Моңарчы әле Киевка җиңелчә кораллар гына бирәләр, күәтле коралларда иске совет техникасын гына китерәләр иде. Вазгыятьнең тагын бер әһәмиятле ягы бар: әлегә кадәр хәрби ярдәм бушлай күрсәтелде. Хәзер коралны башка схема белән китерәчәкләр. Беренчә көн элек АКШ Сенаты «Ленд-лиз турында акт» дип аталган закон проектын кабул итте. Бу закон Байденга Киев белән кичекмәстән корал сату турында килешүләр төзү мөмкинлеге бирә. Ленд-лизның Икенче Бөтендөнья сугышы вакытында СССРга корал сату ысулы буларак майданга чыкканын беләбез. Аның асылы шуннан гыйбарәт: коралны бүген аласың, акчасын соңыннан түлисең. Долларның, алтынның кысрыклап чыгарып, дөньякүләм бердәнбер резерв валютасына әверелүендә ленд-лиз өлеше бар, чөнки СССР Бөек Ватан сугышы елларында алган корал өчен зур күләмдә алтын белән түләргә мәҗбүр булды. АКШ иң күп алтын запасына ия булган дәүләткә әйләнде. Үткән гасырның кырыгынчы елларыннан соң корал ташуның мондый ысулы беренче тапкыр яңадан әйләнеп кайта.

Киевка башка дәүләтләр дә актив коралны ярдәм күрсәтә. Элекке Варшава договоры илләреннән иске совет техникасы китерелә. «Төрек радиосы» апрель башыннан конфликт мәйданында күтәреп йөртелә торган зенит-ракета комплексы Martletның күренә башлавын хәбәр итә. Martlet – кечкенә күләмле күпмаксатлы әдарә ителешле ракета икән. Ул – британ коралы. Бөекбритания хәрбиләре кулына да әле ул 2020 елда гына килеп кергән. Димәк, хәрби бәрелешләрдә беренче тапкыр сынала. Башта ул корабларга каршы ракета буларак эшләнгән.

«Төрек радиосы» да мондый яңа төр коралларның мәйданга чыгуы Көнбатыш коралының Украинага килүендә яңа этап булып торуын ассызыклый.

Искә төшерик: махсус хәрби операция башлангач ук, Россия дипломатиясе Киевка хәрби ярдәм күрсәтелгән очракта тиешле җавап булачагын әйткән иде. НАТО блогы илләренең бу юнәлештә актив эшчәнлек алып баруы конфликтны көчәйтә, аны яңа югарылыкка чыгару ихтималы белән хәвефне арттыра.

Россиядә

ИНФЛЯЦИЯНЕ ЙӨГӘНЛИБЕЗ... 2024 ЕЛДА

Көнбатыш илләре никадәр генә тырышмасыннар, Россияне блокадага алу буенча бердәм фронт булдыра алмадылар. Кытай һәм Һиндстан кебек гигантлар, купчелек Азия илләре Мәскәү белән хезмәттәшлектән баш тартмадылар. Ул гына да түгел, европалылар үзләре, тешләрен кысып булса да, көнчыгыштан килгән углеводородларны алырга мәҗбүрләр. Санкцияләрнең алтынчы пакеты – нефть эмбаргосы турында актив сөйләшүләр алып барылса да, әлегә андый тыюны тормышка ашыру хәлләреннән килми. Апрель аенда Россия рекордлы күләмдә «кара алтын» сата башлаган, диләр. Җир маен зур дисконт белән, ягъни бәясен бик нык төшереп сатарга туры килә. Шул сәбәпле аңа кызыгалар. Хәтта Көнбатышның кайбер компанияләре Россия нефтен башка ил нефте белән кушалар да, яңа сорт китереп чыгарып, «Россиянеке түгел» дип саталар икән. Бу вакытлы гына күренеш булырга мөмкин, билгеле. Иранга санкцияләр кертелгән тә, аның нефтеннән этаплап баш тартканнар.

Нәрсә генә булмасын, агымдагы вазгыять Россия өчен начар түгел. Хәзер инде белгечләр санкцияләр беренче каршка гына дәһшәтле булып күренә, чынлыкта алар алай ук куркыныч түгел, диләр. Душәмбе көнне Путин янында Австрия канцлеры Карл Нехаммер булды. Сөйләшү яшерен рәвештә алып барылды, соңыннан бернинди дә мәгълүмат булмады. Бары тик Нехаммер гына «кырыс шартларда» узуын әйтте. Канцлер, имештер, Көнбатышның кумәк таләпләре белән килгән, Россия лидерын куркытмакчы булган, диләр.

Хәзерге шартларда Россия икътисады үзен ярыйсы хис итә. Валюта курсларының ныгуы импорт товарларга бәя төшүгә өмет уята. Әмма импорт бик нык кыскарды. Чит ил компанияләренең бездән китүе сәбәпле дә, куп кенә товарларның Россиягә кертелүе тыелу аркасында да бәяләр югары кала бирә. Үзебездә җитештерелгән товарлар да февраль башы күрсәткечләренә кайтырга ашыкмыйлар бит.

Россия банкы ел саен инфляция күрсәткечен 4 процентлы чиктә тотарга тырышлана. Алдагы елларда моңа ирешеп булмады: коронавирус аяк чалды. Инде 2022 елда бөгелгә үтибез дигәндә генә санкцияләр белән аркага пычак кададылар. Үзәк банкның 2021 елга хисабы дөнья күрде. Шул уңайдан Эльвира Нәбиуллина мөрәҗәгать белән чыкты. Анда ул регуляторга нинди кыенлыклар белән очрашырга туры килүен аңлата. Хыялдагы 4 процентлык күрсәткечкә бары ирешеп булмый инде. 2023 елда да... Инфляциягә 4 процентлык авызлык кидеру 2024 елга кала. Аңа кадәр бәя күтәрелешенең зуррак процентлары белән эш итәргә туры киләчәк. Путин әле яңа гына гражданнарга һәм бизнеска ярдәм чаралары турында документ имзалады. 20 апрельгә кадәр пенсияләрне, социаль түләүләрне, бюджеттагыларның хезмәт хакларын, хезмәткә түләүнең минималь күләмен (МРОТ) арттыру турында тәкъдимнәр эшләп, Президентка кертү турында әмер бирде. Шулай булгач, Аллаһ теләсә, ач ук булмабыз әле. Түләүләр белән бергә инфляция дә артыр инде. Бәяләр тотрыклылыгы әлегә вәгъдә ителми бит.

МАЙГА КАДӘР ҖИТЕШӘСЕ

Татарстанда салым декларациясен тапшыру вакыты 4 майга кадәр озайтылган. Аңа кадәр аны 30 апрельгә кадәр тапшырып бетерергә кирәк дип хәбәр ителгән иде. Шулай да белгечләр эшне соңгы көнгә кадәр калдырмаска киңәш итә. Россия Салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе Марат Сафиуллин сүзләренә караганда, салым декларациясен май бәйрәмнәренә кадәр тапшырып куйсаң хәерле.

pixabay.com

«4 майга кадәр аерым төркем кешеләр, үзенең конституцион бурычын үтәп, салым оешмасына узган елгы керемнәре турында декларация тапшырырга тиеш», – дип белдерде ул хөкүмәт йортында узган брифингта. Билгеле булганча, эшмәкәрләр, фатир яки бүлмәне арендага бирүдән табыш алган, лотереяда 15 мең сумга кадәр акча откан, якын туганы булмаган кешедән күчемсез милек, транспорт, акция, пай рәвешендә бүләк алган кешеләр 3-НДФЛ декларациясе тапшырырга тиеш. Бу таләп кыйммәтле кәгазь яки үз милкендә биш елдан да ким булмаган мөлкәт саткан кешеләргә дә кагыла.

Әмма бу очракта беренчә искәрмә бар. Агымдагы ел башыннан гамәлгә кергән закон нигезендә кайбер очракларда салым оешмасына декларация тапшырырга кирәкми. «Быелдан башлап, күчемсез милек яки җир участогы сатудан 1 миллион сумга кадәр табыш алган, шулай ук хакы 250 мең сумнан да артмаган башка әйбер, мисал өчен, транспорт яки гараж саткан өчен 3-НДФЛ декларациясе тапшырырга кирәкми», – дип ачыклык кертте Марат Сафиуллин. Ике яки аннан да күбрәк балалы гаилә, фатирын сатып, бер ел эчендә зуррак яңа фатир алып, торак шартларын яхшырткан булса, шулай ук декларация тапшырмый. Алардан аңлатма язуы гына кирәк булачак. Әмма бу мөмкинлектән файдалану өчен, гаиләнең бик күп таләпләргә буенча туры килүе кирәк. Бу очракта фатир мәйданы да, гаиләнең башка милке булу-булмау да исәпкә алына.

Хәзерге вакытта республиканың салым оешмалары барлыгы 200 меңнән артык салым декларациясе кабул иткән. Ай азагына кадәр тагын 70 меңләп кеше салым декларациясе тапшырыр дип көтелә. Бурычлылар да юк түгел. Салым идарәсе мәгълүматларына караганда, бүген республика халкының бер милек салымы буенча гына да 2 миллиард сумнан артык бурычы җыелган. Закон нигезендә андыйларга соңарган һәр ай өчен декларация буенча түләргә каралган сумманың 5 проценты күләмендә штраф яный.

Марат Сафиуллин сүзләренә караганда, Татарстанда салым «вычет»ы кайтаручылар саны да елдан-ел арта бара. Аны алу өчен декларацияне ел азагына кадәр тапшырырга була. Билгеле булганча, безнең хезмәт хакыннан башлап, барлык төр керемнәребездән дә акча тотып калына. Куп очракта шушы тотып калынган салым акчасын кире кайтарырга да мөмкин. Узган ел, әйтик, республикада барлыгы 11,8 миллиард сумлык салым «вычет»ы кайтарылган. Сүз уңаеннан, быелдан башлап төрле фитнес-клубларда, бассейн, спорт залларында шөгыльләнгән өчен түләгән акчадан да салым «вычет»ы кайтарып була. Әмма бу министрлык тарафыннан расланган исемлеккә кергән спорт, сәламәтләндерү оешмаларына гына кагыла. Закон әле быел гына гамәлгә керде. Шуңа күрә 2022 елда сатып алынган юллама өчен салым «вычет»ын киләсе елда гына кайтарып булачак.

Яшерен-батырын түгел, салым «вычет»ы кайтарганда еш кына тоткарлыклар күзәтелә. Салым идарәсеннән «вычет» күчкәнлеге турында хәбәр килә, әмма исәп-хисап счетында акча булмый. Шуннан күпләр пошаманга төшә дә инде. Марат Сафиуллин андый чакта тынычлык сакларга киңәш итә. Бу тоткарлыклар халыкка салым «вычет»ы кайтаручы ике оешма – салым һәм казначылык оешмаларына эшне ахырга кадәр җиткереп бетерү өчен бераз вакыт таләп ителү белән бәйле. «Мондый хәлләр булгалый, әмма «вычет» акчасы барыбер өч көн дигәндә күчәчәк. Ник дигәндә, салым оешмасы барлык документларны тикшергәннән соң, казначылык идарәсенә фәлән физик затка «вычет» акчасын кайтару турында күрсәтмә җибәрә. Аларга исә мондый өчен бераз вакыт кирәк. Шуңа күрә борчылырга кирәкми. Салым «вычет»ы акчасы барыбер күчәчәк», – ди Марат Сафиуллин.

Сүз уңаеннан, белгечләр салым декларациясен электрон рәвештә тапшырырга киңәш итә. Болай эшләгәндә ул салым хезмәте базасында көнендә үк күренәчәк. Кәгазь декларация күренсен өчен исә уртача биш көн вакыт кирәк. Гомумән, салым хезмәте сайтындагы шәхси бит аша хәзер бик куп хезмәтләрдән өйдән чыкмыйча гына да файдаланып була.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Бакчачылар бәхете

Бүгенге хәлләр бакчаларга булган карашыбызны да үзгәртә. Югыйсә соңгы елларда шәһәр янындагы кишәрлеккә ял урыны итеп кенә карый башлаган идек. Быел исә кибетләрдән орлыклар алып, тизрәк кар эреп беткәнне көтә башладык.

Иң мөһиме, бу хакта җитәкчеләребез дә кайгырта. Шул уңайдан «Бердәм Россия» партиясе бакчачылыкка кагылышлы сораулар буенча республика халкын кабул итү атналыгы башлады. Беренче көнне Россия Дәүләт Думасы депутаты Рөстәм Кәлимуллин, Татарстан Дәүләт Советы депутаты Таһир Һадиев, Авыл хуҗалыгы министрлыгының бүлек мөдире Марина Вавилова һәм Татарстан Бакчачылар берлеге идарәсе җитәкчесе Владимир Дейнекин республикада бакчачылыкны үстерү перспективаларын һәм планнарын бәян иттеләр.

Таһир Һадиев әйтүенчә, республика парламенты «Гражданнарның бакчачылыкны һәм яшелчәчелекне алып бару өлкәсендәге аерым мәсьәләләр турында»гы закон проектын беренче укылышта ук яклап чыккан. «Татарстанда Президент Рөстәм Миңнеханов инициативасы белән бакчачыларның проблемаларын хәл итү өчен 550 млн сум акча бүлеп бирелде, – диде ул. – Шулай ук бакчачыларның эшчәнлегенә субсидия бирү мөмкинлеге пәйда булды. Республика бюджетыннан да 700–750 млн сумлык ярдәм күрсәтеләчәк. Бу – бик зур сумма».

Владимир Дейнекин исә: «Бакчачылык-яшелчәчелек хуҗалыкларына тәгаенләнгән мондый ярдәмнең моңа кадәр булганы юк иде әле, Россиянең башка төбәкләрендә дә аның күләме бик кечкенә, еш кына 50 млн сумнан артмый, – дип сөенде. – Без инде бакчачылыкның һәм яшелчәчелекнең социаль яктан әһәмияте бик зур, дип гел әйтә киләбез. Президентның, хөкүмәтнең, Дәүләт Советының да шундый фикердә булуы – безнең өчен зур бәхет».

Бакчаларда эшне тагын да тагын да җанландыру өчен яңалыклар да кертергә җыеналар. Мәсәлән, комплексы үзанлаштыру программасын сынап карарга уйлыйлар. Моның өчен пилот район билгеләнгән дә инде. Бу хакта Марина Вавилова сөйләде. Дөрес, мондый чара үткәрергә кирәклеге турында узган елда ук сүз күзгатылган иде инде. Белгечләр бу гамәлне, су скважиналарын теркәү өчен кирәк, дип аңлаталар. «Закон буенча скважиналар ширкәт әгъзаларының милке булып торырга тиеш. Моның өчен гомуми файдаланулы булган җирләрне үзанлаштырырга һәм теркәргә кирәк. Бу исә элеккеге үзанлаштыру эшләрендә киткән хаталардан котылырга (участокларның күршеләренә яки гомуми файдаланудагы җирләргә «сикерү» очраклары еш очрый) ярдәм итәчәк. Комплексны үзанлаштыру үткәрелгән очракта шәхси участоклар, гомуми файдаланудагы җирләр – барысы да үз урынында булыр иде. Комплексны үзанлаштыру шулай ук юлларга, инфраструктура объектларына ремонт ясау, чүп сабылырын кую эшләрен дә җайга салачак», – диде Марина Вавилова.

Әйтергә кирәк, бакча эшләре күпләрне кызыксындыра. Сорау бирүчеләр дә шактый. Закон проектына саллы гына тәкъдимнәр дә булды. Төбәк иҗтимагый кабул итү бүлмәсе җитәкчесе Камил Садриев, аларның бирсен дә игътибарсыз калдырмыйбыз, дип ышандырды.

Бу – зур эшнең башы гына әле. Җитәкчеләр дә битараф булмагач, күңелдә, димәк, тиздән без үзебез үстергән яшелчә, җиләк-җимешләрне күбрәк ашый башларбыз, бала-оныкларыбыз эшкә өйрәнеп үсәр, дигән өмет ныгый.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Батырлыкка соклану

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

– Бала вакытта гына аралашырга туры килде шул аның белән. Шуңа да карамастан, Дамирның үлеме турында ишетү кыен булды. Күпме гомер узган, диярсең. Хәтеремдә киң күңелле, нурлы, тыйнак, булышырга әзер торган егет булып уелып калды. Аның турында начар сүз әйтерлек тә түгел... 2003 елда балалар бакчасында чыгарылыш кичәсендә миңа Дамир белән парлы бию бакчаларга насыйп булды. Мәктәп яшендә бик якын аралашмадык шул. Кызганыч... Гаиләсенә сабырлык телим, – диде Элина.

– Без Дамир белән иң якын дуслар булдык. Бу шулай калачак та. Без аның белән горурландык. Мин моны барлык дуслары исеменнән әйтә алам. Безнең өчен үрнәк ул. Ярдәмчел булуы, миһербанлылыгы өчен рәхмәт аңа. Берәү дә хәтерләргә ирек куймас: Дамир акыл, яхшы күңелле, шаян егет иде, – ди аның хакта сыйныфташы Альмир Ямалиев.

Генерал-майор, Казан югары танк команда училищесы башлыгы Кирилл Кулаков та элеккеге курсантның асыл сыйфатларын телгә алды.

– Без укучыбыз Дамир Исламов белән горурланабыз. Аны башка курсантларга, хәтта офицерларга үрнәк итеп куябыз. Ул – чынлап та, лаеклы офицер, уз иленең лаеклы улы. Үзенең экипажы белән оста идарә итте, куелган бурычны үтәде, – диде ул.

ФӘРИТ ХӘЙРЕТДИНОВ:

«БЕЗНЕКЕЛӘР ДӘ ЧӘЙНӘРГӘ ӨЙРӘНЕРЛӘР»

ҮЗГӘРЕШЛӘР «КӘҮСӘР» КООПЕРАТИВЫНА ЙОГЫНТЫ ЯСАГАНМЫ?

Эт һәм мәчеләр өчен чит ил азыклары кертелми башлагач, Лаеш районының Рус Никольское авылындагы «Кәүсәр» кооперативы дүрт аяклы дусларыбыз өчен үрдәк итеннән азык җитештерә башлаган. Ветеринария тикшерүләрен инде узганнар, әлеге көннәрдә кооператив яңа төр азыкка сертификация көтә. Димәк, тиздән кибет киштәләрендә йорт хайваннары өчен үзебездә җитештерелгән ризыклар пәйда булачак.

«Татар-информ»

Яңа цехны журналистларга да күрергә насыйп булды. Производство директоры Андрей Герасимов әйтүенчә, алар әлеге эшкә барысын да алдан уйлап алганнар.

– Этләре булган кешеләр чит ил азыкларын бетүдән курка, – ди ул. – Без исә белгечләр белән киңәшләштек тә үзебез азык җитештерергә булдык. Азык тулысынча пешерелгән, стерильләшкән, ягъни кулланучга әзер. Хәтта суыткычта да сакларга кирәк булмаячак. Алар 360 граммлы һәм кечкенә банкаларда саклана. Сату нокталарына озатылганчы да продукт 14 тәүлек сынау уза. Бу азыкның сыйфатын тикшерү өчен кирәк. Этләр һәм песиләр дә дөрес тукланырга тиеш, дип уйлыйбыз. Шуңа күрә азык составында үрдәк бавыры, бераз гына ярма, яшелчәләр, витаминнар, аминокислоталар бар. Ә тоз, борыч безнең кулланмады. Өч килограммлы йорт хайваны өчен 100 грамм азык җитәр дип уйлыйбыз.

Куплап җитештерүгә керешкәнче, приютларга барып, андагы этләрне ашатканнар. Бәясенә килгәндә, әлегә төгәл мәгълүмат булмаса да, чит илнекеләр белән чагыштырганда, арзанрак чыгар, дип ышандыра белгеч.

– Ризыкның үзкыйммәтенә килгәндә, куплап сату бәясе 120 сум тирәсе булыр, – диде Андрей Герасимов.

Кооператив әлеге юнәлеш буенча КХТИ белән дә актив эшли. Уку йортының азык-төлек технологияләре кафедрасы мөдире, эт тәрбияләүдә бөтенроссия эксперты Мстислав Поливанов үрдәк итеннән ясалган азыкны үз этләренә ашатып караган.

– Иң яхшысы – үзең сынап карагач мактау. Яшьрәк этка – ат ите, өлкәнрәгенә – үрдәк ите бирәм. Бик яратып ашыйлар, – диде ул.

«Бәйрәмнәр ешрак булсын»

«Рамай» хуҗалыгы үз эшчәнлеген тугыз ел элек үрдәк ите җитештерүдән башлап җибәргән. Хәзер исә кооператив итеп оешып, эшчәнлекләрен тагын да җәелдергәннәр: сыер, ат, сарык итеннән дә ризыклар ясыйлар. Барлыгы 84 төрдәге азык әзерләнә. Сатып алучыларга камыр белән эшләнгән сигез төрле ярымфабрикат тәкъдим итәләр: пилмән, хинкали, мантый, өчпочмак, бәлеш, самса, чебурек һәм башкалар.

– Бер эшче көненә 45–50 кг пилмән ясый. Башка ризыклар зуррак күләмдә эшләнә. Гомумән алганда, көненә якынча 400–600 кг ярымфабрикатлар ясыйбыз. Заводның исә бер сменада 1 тонна ярымфабрикат ясау мөмкинлеге бар, – ди Андрей Герасимов.

Заводта җитештерелгән ризыклар егерме градус суыкта саклана. Аннан кала, 35 градуста туңдыра торган шокерлары да бар. Андрей Герасимов әйтүенчә, мондый ысул белән катырылган ит сусыз, тәмлерәк була.

Бирегә һәр цехта зур-зур иттарткычлар, җиһазлар, суыткычлар, туңдыргычлар, ит каклау камералары эшли. Итләрне сәяхләреннән арындырып, фарш ясыйлар. Тагын бер булектә колбасалар ясыйлар. Азык сусыл, тәмле булып чыксын өчен, аны 6–7 сәгать түбәнрәк температурада парда пешерәләр. Шуннан соң, суытылып, төргәкләүгә җибәрелә. Шулай ук үрдәкнең түш ите дә, һавасы чыгарылып, төргәкләргә тутырыла.

«Рамай» компаниясе директоры, «Кәүсәр» кооперативы рәисе Фәрит Хәйретдинов сүзләре буенча, сыер, ат, сарык, үрдәк һәм каз ите белән эш итсәләр дә, өстенлекне үрдәккә бирәләр.

– Үрдәк – бәйрәм ите, татарлар үрдәк ярата. Без кеше өчен бәйрәмнәрнең ешрак булуын телибез. Шуңа күрә кошларны 4–5 елда бәяләрне дә күтәрмәдек. Ә кошларны үзебез үстерәбез. Токымнарны ел саен алыштырабыз. Моңа кадәр инглиз токымын үрчеткән идек, хәзер француз токымы белән эшлибез. Ел саен август һәм сентябрь айларында ата һәм ана үрдәкләр алып кайтабыз, алар 1,5 ел йомырка сала. Киләсе елның маена кадәр җитәрлек кошыбыз бар, – ди Фәрит Хәйретдинов.

Аның аңлатуынча, чит илдә селекция, токым белән шөгыльләнгәннәр. Ягъни кошларның «абый» белән «сеңел»ләрен катнаштырмаганнар, ин яхшыларын сайлаганнар.

– Шуңа күрә алар бөтенләй башка. Итләречәк, майлырак. Итләре дә, майлары да тәмлерәк, яхшырак, сыйфатлырак, – ди ул. Җитәкче сүзләренчә, заводта елына 4–5 мең тонна үрдәк ите җитештерелә.

Кыскасы, «Кәүсәр» кооперативы җитәкчелеге, илдәге вазгыять үзләренә артык зур йогынты ясар, дип уйламый.

– Немецлар ясаган запас частьларны безнекеләр дә ясар, дип уйлыйм. Безнекеләр ихтыяҗ юк иде, хәзер зур булыр. Элек Көнбатыш чәйнәп биргәндә, чәйниселәре килми иде, хәзер тешләре барлыкка килер дә, чәйни башларлар, – диде Фәрит Хәйретдинов.

Зәһрә САДЫЙКОВА

АЛЕКСАНДР ЛАТЫШЕВ:

«РЕСПУБЛИКА ТАРИХЫ БЕЗДӘ ЯЗЫЛА»

Әңгәмә

Бүген – күршеләрдә бәйрәм. «Республика Татарстан» газетасы чыга башлауга 105 ел тула. Ул вакытта «Рабочий» дип аталган газетаның тәүге саны 1917 елның 13 апрелендә дөнья күрә. Үз тарихында алты мәртәбә исем алмаштырган басманың баш мөхәррире Александр ЛАТЫШЕВ белән әңгәмәдә узганга сәяхәт кылып, киләчәкне фаразларга тырыштык.

Илдар Мөхәммәтҗанов

:: Александр Николаевич, басма матбугатның бетәсен инде күптән фаразлыйлар. Ә сез 105 еллыкны бәйрәм итәсез...
– Мин журналистикада инде 50 елдан артык эшлим. Шуның 19 елы – «Республика Татарстан»да баш мөхәррир булып. Газеталар бетәсен күптән әйтәләр һәм бу – чынбарлык. Моңа үпкәләргә дә, каршы килергә дә кирәкми. Алгарышны туктатып булмый. Әмма кайчан бетәр? 15 ел элек укыган бер китапта 10 елдан дип язылган иде. Инде аннан соң да 5 ел узган, әле үләргә җыенмыйбыз. Әйе, газетаның бурычлары үзгәрә. Ленин ничек әйткән әле? Газета ул – коллектив пропагандист һәм агитатор гына түгел, коллектив оештыручы да. Хәзер без күбрәк тасвирлау белән шөгыльләнәбез, елъязмачыга әверелеп барабыз сыман. Миңа калса, бер начарлыгы да юк. Газетабызның 105 еллык архивы урнашкан бүлмәне мин «алтын бүлмә» дип атыйм. Әйе, совет заманында газета чыгарганда идеология исәпкә алынган. Хәзер объективрак. Ничек кенә булмасын, газетада язылганнарга карап, илнең нинди тормышта яшәгәнен чамалап була. Архив та, телевидение дә, башка матбугат та бу эшне газете кебек системалы рәвештә алып бара алмый. Газетаның эчтәлеге – республика биографиясенең эчтәлеге ул.

Газета бетүдән куркырга кирәкми. Иң мөһиме: аннан соң ни булачак? Менә шуларга әзер булып торырга кирәк.

:: Заманасы да, укучысы да үзгәреп тора. Әйтик, хәзер тормышны интернетсыз күз алдына да китереп булмый. Сезнең нинди фикерләр бар?
– Идеяләр күп, әмма аларны тормышка ашыру өчен финанс мөмкинлекләре дә кирәк. Без бит коммерциягә газета да, сары матбугат та түгел. Нииндидер вакыйгаларны күпертеп, акча эшли алмыйбыз. Объектив булырга, төп функциябезне үтәргә – Татарстан Президенты, Дәүләт Советы, Хөкүмәтнең эшчәнлеген күрсәтергә тырышабыз. Әйе, бу гади укучыга кайчак бик үк кызык та булмаска мөмкин. Әмма республика җитәкчелеге башкарган эшне, алар җитәкчелегендә безнең кая таба баруыбызны тагын кем сөйли ала? Бездән башка беркем дә! Бу яктан караганда, бәлки, кемгәдер оттырабыздыр да. Әмма оттыру әле ул дөрес эшләмибез дигән сүз түгел. Әйтәм бит, киләчәктә үткәнне безгә карап өйрәнәчәкләр. Җинаятьчелек турындагы хәбәрләр белән генә тираж ясап булмый.

«Республика Татарстан»ның киләчәген басма матбугат, электрон матбугат, социаль челтәрләрне берләштергән редакцияләр комплексы итеп күрәм. Әлегә төп игътибарны басма матбугатка бирәбез. Әмма вазгыять үзгәреп тора, шуңа соңга калырга да ярамый. Киләчәктә нияләр килеп чыгасын күз алдына да китереп булмый. Берничә ел элек кенә социаль челтәрләр турында ишеткән дә юк иде. Ә хәзер каргызы: ниләр булып ята? Әйбәтме ул, юкмы – озак бәхәсләшергә була. Миңа калса, социаль челтәрләр чүп үлән басып киткән болын-кыр кебек. Матур чәчәкләр дә бар, әмма аны бик озак эзләргә кирәк. Ә без мәгълүматны сайлап, тикшереп бирергә тырышабыз.

:: Ә дөрес мәгълүматны кайдан алырга?
– Матбугат ирегә турында сөйлиләр. Берәүләр, бар, ди, икенчеләр каршы чыга. Ничек кенә булмасын, аңа омтылырга кирәк. Дөрес мәгълүмат та шуның кебек. Аңа омтылырга кирәк.

Телибезме-юкмы, Украинадагы вакыйгаларны искә алырга туры килә. Хәрби операция, миңа калса, уңышлы бара. Ә менә мәгълүмат сугышында хәлләр башкачарак. Бер сәбәбен әйтәм. Чөнки 1991 елда бездә идеология дигән төшенчә бөтенләй юкка чыкты. Бик зур хата булды бу. Изге урын буш тормый, аның урынына башкасы килә. Хәзер әнә шул хатаның җимешләрен татыйбыз. Бик күп алар. Әйтик, яшь буынны тәрбияләү. Совет заманын сагынып сөйләвем түгел, гадел бәя бирергә тырышам. Әйе, арттырып җибәрүләр дә күп иде. Моны ул заманнарда партия органнарында эшләгән кеше буларак әйтә алам. Әмма шул ук октябрят, пионер, комсомоллар, ягъни система бар иде. Ә бүген аны һаман кора алмыйлар. Министрлыклар, оешмалар бик күп, система юк.

:: Меңьеллык, Универсиада һәм башка зур чаралардан соң безне берничек тә гаҗәпләндереп булмас кебек тоелган иде. Алай түгел икән. Ике ел элек бу вакытта коронавируска каршы көрәшә башладык, быел – Украина конфликты... Бу вакыйгаларны журналистлар ничек кичерә?
– Эшебез җиңел түгел. Коралны Көчләргә теләктәшлек күрсәтү, җәмгыятьтә бердәмлек һәм тынычлыкны саклау, ялган хәбәрләргә һәм коткыга каршы тору өчен тырышабыз. Тарих языла.

Журналистларның һәрберсе – аерым кеше. Һәрберсенә сынаулар аша узарга туры килә. Алар робот түгел, вакыйгаларны төрлечә кабул итәләр. Шул ук Украинадагы хәлләрне берәүләр, кем әйтмешли, быргылар кычкыртып, барабаннар кагып кабул итә. Ә улы хәрби хезмәттә булган кеше башкачарак фикер йөртә. Ләкин без бердәм булырга тиеш. Моны мин матур сүз булсын дип түгел, ә киләчәккә өмет белән әйтәм. Артка юл юк.

«Журналист» төшенчәсе нык үзгәрде. Мин моны яшьләргә карап та әйтә алам. Эш кемнең әйбәтрәк, кемнең кайтышрак булуында түгел. Заманасы да, кешеләре дә башка чөнки. Тәрбия дә, технологияләр дә үзгәрде. Бүгенге буынны мактап яки тәнкыйтьләп утырасы түгел, ә кем бар, шулар белән эшләргә кирәк. Бик өметле егетләр һәм кызлар килә. Әмма бүгенге яшьләр бер урында тик утыра алмый. Матур гына эшли башлыйлар да, китеп тә баралар.

:: 105 еллык алдыннан нинди нәтиҗәләр ясыйсыз?
– Бу газетаның гаҗәеп тарихы бар. Кемнәр генә килеп китмәгән дә, нинди генә вакыйгалар булмаган! 1991 елда редакциягә эшкә килгәч, иске генә бер урындыкка игътибар иттем. Безгә бит язучы Максим Горький да килеп йөргән. Элеккеге фоторәсемнәрнең берсен караганда, Горькийның нәкъ менә шул тарихи урындыкта утырганына игътибар иттем. Дәүләт музеена тапшырдык, хәзер ул шунда саклана. Язучы Демьян Бедный ике атна эшләп киткән. Бөек Ватан сугышы вакытында Чистайда яшәгән бик күп язучылар безнең редакция белән хезмәттәшлек иткән. Василий Аксеновның әнисе Евгений Гинзбург бездә эшләгән. Хәбәрчебез Ян Винецкийның «Литературная газета»да язмасы чыккач, Михаил Девятаевка Советлар Союзы Герое исеме бирелә. Танылган сәясәтче, хәзер Дәүләт Думасының контроль комитеты рәисе Олег Морозов заманында безнең сәяси күзәтүче булып эшләде. Шәхесләрнең барысын да санап чыгу бик күп вакытны алыр иде. Газета кешенең талантын, тырышлыгын ала, икенче яктан, ул үзе дә кешеләргә күпне бирә.

Әңгәмәдәш – Илнар ХӨСНУЛЛИН

КОТЛЫЙБЫЗ!

«Кичүчәт» җаваплылыгы чикләнгән авыл хуҗалыгы җәмгыяте баш агрономы (Татарстан Республикасының Әлмәт районы) **Мортазин** Ривгат Минзакир улына, «Россия авыл хуҗалыгы үзәге» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалы Менделеевск район бүлеге баш агрономы **Токарев** Николай Михайловичка **«Татарстан Республикасының атказанган агрономы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Россия өзлексез һөнәри белем бирү медицина академиясе» федераль дәүләт бюджет өстәмә һөнәри белем бирү мәгариф учреждениесе филиалы – Казан дәүләт медицина академиясе директорының фән һәм үсеш буенча урынбасары, неврология кафедрасы доценты **Әхмәтова** Гүзәл Марс кызына, Казан шәһәренең «20 номерлы шәһәр поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибының клиника-эксперт эше буенча урынбасары **Галина** Ләйлә Зариф кызына, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика балалар клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең 1 номерлы анестезиология һәм реанимация бүлекчәсе табибы – анестезиолог-реаниматологы **Когуашвили** Георгий Елгудзовичка, Казан шәһәренең «7 номерлы шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибының медицина часте буенча урынбасары **Мельников** Евгений Анатольевичка, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика балалар клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе поликлиникасы мөдире – 1 номерлы консультация поликлиникасы табиб-педиатры **Пятеркина** Оксана Геннадьевнага, «Профессор А.Ф. Агафонов исемендәге Республика йогышлы авырулар клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе бүлекчә мөдире – табиб-инфекционисты **Шәрифуллина** Гөлнара Салих кызына **«Татарстан Республикасының атказанган табибы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Тимирязев исемендәге җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең терлек караучысы (Татарстан Республикасының Балтач районы) **Гыйльметдинова** Фирая Вазыйх кызына, «Вахитов исемендәге» авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативы бозау караучысы (Татарстан Республикасының Кукмара районы) **Кәримуллина** Гөлфия Мәгъсүм кызына **«Татарстан Республикасының атказанган терлекчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Игенче» авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативы тракторчы-машинисты (Татарстан Республикасының Балтач районы) **Абдуллин** Газинур Камил улына, «Арбор» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте механизаторы (Татарстан Республикасының Балтач районы) **Хәбибуллин** Илсур Рәхимулла улына **«Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы механизаторы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Сәмил» авыл хуҗалыгы предприятиесе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең кадрлар буенча белгече (Татарстан Республикасының Балтач районы) **Кашапова** Гөлсимә Барый кызына, «Сафин Марат Салихҗан улы» крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы (Татарстан Республикасының Аксубай районы) **Сафин** Марат Салихҗан улына, «С.-Омга» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры (Татарстан Республикасының Әгерҗе районы) **Харисов** Разиф Гатуф улына, «Вафин Радик Кадыйр улы» крестьян (фермер) хуҗалыгының яшь терлек карау буенча операторы (Татарстан Республикасының Лаеш районы) **Харисов** Рамель Сәлим улына, «ТӨНЬЯК» АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ПРЕДПРИЯТИЕСЕ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте баш инженеры (Татарстан Республикасының Арча районы) **Йосыпов** Самат Сафәргали улына **«Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим кертү турында

№ 319 Казан шәһәре 2022 елның 6 апреле

«Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясы һәм «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1993 елның 18 маендагы 1866-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 25 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты **КАРАР БИРӘ**:

1. 2022 елның 25 апреленнән 15 маена кадәр Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим урнаштырырга.

2. Янгынга каршы махсус режим гамәлдә булган чорда тыярга:

учаклар ягуны, каты көнкүреш калдыкларын, коры үләнне һәм чүп-чарны яндыруны;

урман янгыннары һәм башка ландшафт (табигый) янгыннары куркынычы янаган торак пунктлар территорияләрендә, бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәтләрендә, балаларның ял итү һәм аларны савыктыру оешмалары территорияләрендә, шулай ук урман массивлары белән чиктәш икътисад объектларында махсус янмый торган савытларда (мангал, жаровняларда һ.б.) ризык әзерләү, башка җайланмаларда ризык әзерләү өчен (җәмәгать тукլануы объектлары (рестораннар, кафе, барлар һ.б.) территорияләрендә урнашкан һәм эксплуатацияләнә торган мангаллар һәм башка җайланмалардан тыш) ачык ут куллануны;

урман янгыннары һәм башка ландшафт (табигый) янгыннары куркынычы янаган торак пунктлар территорияләрендә, балаларның ял итү һәм аларны савыктыру оешмалары территорияләрендә, бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәтләре, сәламәтләндерү оешмалары, шулай ук икътисад объектларында, урман парк зоналарында, торфлы участокларда һәм урман массивлары белән чиктәш ачык территорияләрдә куркынычлык дәрәҗәсе 1–3 класс булган пиротехник эшләнмәләрне куллануны;

аларның югарыга күтәрелү принцибы ачык ут ярдәмендә конструкцияләр эчендә һава җылытуга нигезләнгән, янучан материаллардан булган идарә ителми торган эшләнмәләрне җибәрүне.

3. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына:

ведомство карамагындагы объектлар территорияләрен коры үләннән һәм чүп-чардан чистарту буенча чаралар күрергә;

баланста булган тышкы янгынга каршы су белән тәэмин итү чыганакларының эшкә яраклылыгын тикшерергә;

янгынга каршы махсус режим гамәлдә булган чорда янгын куркынычы янаган эшләрне үткәрүне чикләргә.

4. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына, шулай ук Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә тәкъдим итәргә:

привентив янгын-профилактик чаралар комплексын планлаштырырга һәм үткәрергә;

массакүләм мәгълүмат чараларында торак пунктларның янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүдәге проблемалы мәсьәләләрне яктыртырга, шулай ук янгын куркынычы янаган чорда халыкка янгын куркынычсызлыгы чаралары турында хәбәр итәргә.

5. Тәкъдим итәргә:

Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә:

башкарма комитет җитәкчеләренә, бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләре рәисләренә, балаларның ялы һәм аларны савыктыру оешмалары җитәкчеләренә урман янгыннары һәм башка ландшафт (табигый) янгыннары куркынычы янаган торак пунктларның паспортларын эшләүдә (актуальләштерүдә), урман янгыннары куркынычы янаган бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләре территорияләрен, балалар ялын оештыру һәм аларны савыктыруны оештыру оешмаларына консультатив һәм методик ярдәм күрсәтергә;

торак пунктларны, бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләрен, икътисад объектларын урман янгыннарыннан һәм башка ландшафт (табигый) янгыннарыннан саклауны контрольгә алырга, шулай ук урман янгыннары чыганакларын һәм башка ландшафт (табигый) янгыннарын үз вакытында ачыклау һәм аларны ачыкланган көнне бетерү эшен оештырырга;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә янгынга каршы режим кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 номерлы карарын исәпкә алып, корыган үлән, үсемлекләрне яндыру тәртибен аңлату эшен оештырырга;

урман янгыннары куркынычы янаган бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәтләре рәисләре белән янгын куркынычсызлыгы чаралары буенча киңәшмәләр үткәрергә;

космик мониторинг чаралары тарафыннан табылган янгыннар (термик нокталар) турында сигналларга вакытында җавап бирүне тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыкларына:

урман янгыннары һәм башка ландшафт (табигый) янгыннары куркынычы янаган торак пунктларда вакытлыча янгынга каршы постлар булдырырга;

торак пунктларны янгыннан саклауны ныгытуга юнәлдерелгән, шул исәптән чүп-чар, үлән, корыган яфраклар һәм башка калдыкларны, материалларны һәм эшләнмәләрне яндыру урыннарын һәм алымнарын билгеләү буенча муниципаль хокукый актлар кабул итәргә;

коры үләнле урыннарны ачыклау, шулай ук янгын очракларына оператив җавап бирү максатыннан һәр авыл җирлегендә патруль-контроль төркемнәре булдыру һәм аларның эшен оештыру, бу төркемнәрнең эш графикларын эшләү һәм янгын куркынычы янаган чорга кадәр аларны Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына тапшырырга;

торак пунктлар, бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләре территорияләрендә янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәү һәм янгын килеп чыкканда гамәлләр тәртибе буенча халык белән аңлату эшләре алып барырга, бу юнәлештә массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара бәйләнешне оештырырга;

янгын куркынычы сезоны башланганчы торак пунктларны һәм икътисад объектларын урман янгыннарыннан һәм башка ландшафтлы (табигый) янгыннардан саклау өчен минераллаштырылган полосалар булдырырга, территорияләрне коры үлән-үсемлекләрдән, ауган агачлардан, чүп-чардан һәм башка янучан материаллардан, бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләре территорияләрендә хуҗасыз һәм озак вакыт файдаланылмый торган җир кишәрлекләреннән чистарту эшләрен төгәлләргә;

гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча комиссия утырышларында торак пунктларның янгын куркынычсызлыгы торышы турындагы мәсьәләләрне карарга;

янгын автомобильләре белән су алу өчен табигый һәм ясалма сулыкларны һәм аларга керү юлларын төзек хәлдә тотуны тәэмин итү;

гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системаның муниципаль звенолары көчләренең һәм чараларының табигать янгыннарын сүндерүгә әзерлеген тикшерү уздыру;

урман янгыннары хәле катлауланган чорда ирекле һәм муниципаль янгын сагы әгъзаларының тәүлек буе кизү тору планнарын төзергә, шулай ук су сиптерү һәм янгын сүндерү өчен җайлаштырылган башка техниканы җәлеп итү планнарын төзергә;

табигать янгыннары белән бәйле гадәттән тыш хәлләрне бетерү, торак пунктларны, икътисад һәм социаль инфраструктура объектларын урман янгыннарыннан саклау, шулай ук урман янгыннарын һәм башка ландшафт (табигый) янгыннарын сүндерү өчен билгеләнгән көчләрне һәм чараларны муниципальара маневрлаштыру буенча комплекслы өйрәнүләр үткәрергә;

урман янгыннары һәм башка ландшафт (табигый) янгыннары килеп чыккан очракта халыкка хәбәр итү һәм аларны эвакуацияләү мәсьәләләрен эшләргә;

кешеләрне вакытлыча урнаштыру пунктларының янгын куркынычы янаган чорда эшләргә әзерлеген тикшерү;

эвакуацияләнгән халыкның беренче чиратта яшәешен тәэмин итү планнарын эшләү;

янгын турында хәбәр итү чараларының тотрыклы эшен тәэмин итәргә;

урман янгыннары һәм башка ландшафт (табигый) янгыннары барлыкка килгәндә һәм барлыкка килү куркынычы янаганда «Югары әзерлек» һәм (яки) «Гадәттән тыш хәл» режимнарын үз вакытында кертүне тәэмин итәргә;

торак пунктлар, шәхси йортлар территорияләрен коры үләннән һәм янучан чүп-чардан вакытында чистартуны, шулай ук махсус билгеләнмәгән урыннарда учаклар ягуны булдырмау өлешендә муниципаль берәмлекләрнең административ комиссияләре эшен активлаштырырга;

Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Идел-Кама төбәкара идарәсенә, «Түбән Кама» милли паркы һәм Идел-Кама дәүләт табигый биосфера тыюлыгы җитәкчеләренә:

янгын куркынычы сезоны башланганчы махсус урман янгыннарын сүндерү техникасын һәм җайланмаларны төзекләндерергә, махсус саклана торган табигать территорияләре чикләрендә янгынга каршы профилактик чаралар комплексының үз вакытында үтәлешен тәэмин итәргә;

республиканың җирле үзидарә органнарына торак пунктларның урман массивларына кушылу чикләре буйларындагы минераллаштырылган полосаларны төзекләндерүдә ярдәм күрсәтергә;

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына янгынның һәр факты турында оператив мәгълүмат бирергә;

«Россия тимер юллары» ачык акционерлык җәмгыяте филиалы – Горький тимер юлының Казан бүлекчәсенә янгын куркынычы сезоны башланганчы тимер юлларга бүлеп бирелгән полосаларда янгынга каршы профилактик чаралар комплексын үз вакытында үтәүне тәэмин итәргә, шулай ук тимер юлларга бүлеп бирелгән полосаларда янгын очраклары турында Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына оператив мәгълүмат бирергә.

6. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына:

муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары белән берлектә урман янгыннарын профилактикалауга һәм алар белән көрәшкә юнәлдерелгән оештыру-техник чаралар үткәрүне тәэмин итәргә;

урман массивларында һәм алар янында урнашкан табигый һәм ясалма сулыклардан янгын сүндерү техникасы белән су алу өчен мәйданчыклар төзүне дәвам итәргә;

урман янгыннарын башлангыч стадиядә ачыклауга, локальләштерүгә һәм бетерүгә юнәлдерелгән оператив чаралар күрүне тәэмин итәргә;

урман янгыннарын сүндерү өчен янгынга каршы техниканы, транспорт чараларын, шулай ук урман янгыннарын сүндерү планнары нигезендә юридик затларны һәм гражданнарны җәлеп итәргә;

республиканың җирле үзидарә органнарына торак пунктларның урман массивларына кушылу чикләре буйларындагы минераллаштырылган полосаларны төзекләндерүдә ярдәм күрсәтергә;

янгын куркынычы сезоны башланганчы:

урман янгыннарын сүндерү формированиеләрен билгеләнгән норма-тивларга туры китереп шәхси состав белән комплектлаштырырга, шәхси составны укытуны оештырырга;

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына караган дәүләт бюджет учреждениеләре карамагындагы махсус урман янгыннарын сүндерү техникасын һәм җиһазларын техник яктан төзек хәлгә китерергә.

7. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына торак пунктларда һәм урман массивларында янгыннарны кисәтү максатыннан чаралар күрергә:

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә янгынга каршы режим кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 номерлы карарын исәпкә алып, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдә һәм запастагы җирләрдә ачык ут куллану һәм учаклар кабызу тәртибен ведомство буйсынуындагы учреждениеләр җитәкчеләренә җиткерү;

авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдә һәм алар янәшәсендәге урман массивларында язгы кыр эшләре һәм урып-җыю эшләре вакытында авыл хуҗалыгы оешмалары һәм фермер хуҗалыклары тарафыннан урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәүгә юнәлдерелгән чаралар комплексын гамәлгә ашыру;

авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдә коры үлән, калдыклар һәм агач-куак үсемлекләргә ут төртүне булдырмау;

басу-кырларның һәм торак пунктларның урман һәм торф массивларына, дала полосасына, автомобиль һәм тимер юлларга терәлеп торган урыннарын сөрү;

авыл хуҗалыгы оешмалары территорияләрен чүп-чардан һәм корыган үләннән чистарту, авыл хуҗалыгы формированиеләре балансында булган, янгын сүндерү максатлары өчен яраклаштырылган техниканы тәүлек буе (кирәк булганда) кизү торуны оештыру, шулай ук төзек булмаган янгын техникасын ремонтлау буенча.

8. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына, шулай ук табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Идел-Кама төбәкара идарәсенә һәм Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә тәкъдим итәргә:

2022 елның 30 апреленнән 11 маена кадәр янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәү буенча гражданнарның күпләп ял итү урыннарына һәм урманнарга патрульлек итәргә;

урман янгыннары белән бәйле гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда һәм килеп чыгу куркынычы барлыкка килгәндә халыкка гамәлләр алгоритмы буенча массакүләм мәгълүмат чаралары аша мәгълүмат җиткерүне оештырырга;

халык арасында, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чаралары аша торак пунктларда һәм урманнарда язгы-җәйге чорда янгыннарны профилактикалау мәсьәләләре буенча максатчан эш оештырырга;

гражданнар җыеннарында янгыннарны сүндерү һәм гадәттән тыш хәл зо-насыннан эвакуацияләү буенча гамәлләргә өйрәтү буенча дәресләр үткәрергә;

урман янгыннары һәм башка ландшафт (табигый) янгыннарының торак пунктларга һәм икътисад объектларына күчү куркынычы янаганда практик гамәлләрне эшләү белән муниципаль, ведомство, шәхси һәм ирекле янгын формированиеләренең, урман янгыннары формированиеләренең әзерлеген тикшерүне оештырырга.

9. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына, законнарда каралган тәртиптә, урман-парк зоналарына һәм гражданнар күпләп ял итү урыннарына патрульлек итү чорында-Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына, Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә һәм табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Идел-Кама төбәкара идарәсенә ярдәм итәргә тәкъдим итәргә.

10. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына:

янгын куркынычы сезоны башланганчы төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлларын төзекләндерү элементлары һәм бүлеп бирелгән полосаларны янгынга каршы саклау чараларын күрергә;

төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлларын, юл читләрен чүп-чардан, үлән һәм агач-куаклардан системалы чистартуны тәэмин итәргә.

11. «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына:

язгы-җәйге чорда торак пунктларда һәм урманнарда янгын куркынычсызлыгын пропагандалаучы видео- һәм аудиороликлар эшләргә һәм аларны республика, шәһәр һәм җирле теле- һәм радиоканалларда («Татмедиа» акционерлык җәмгыяте филиалларында) трансляцияләүне оештырырга;

массакүләм мәгълүмат чараларында халыкның куркыныч янаганда үз-үзен тотышы кагыйдәләрен бастырып чыгару белән «ГТХМ кисәтә» профилактик рубрикасын оештырырга.

12. Балансында урман янгыннары куркынычы янаган, балаларның ялын һәм аларны савыктыруны оештыру оешмалары булган дәүләт хакимияте башкарма органнары җитәкчеләренә:

янгынны үз вакытында ачыклау өчен оешмаларның вазыйфаи затлары арасыннан патруль төркемнәре булдыру;

янгын чыгу турында җирле үзидарә органнарына, Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына хәбәр итү тәртибен эшләргә;

табигый (урман) янгын килеп чыккан очракта, хәбәр итү һәм оешма территориясеннән балаларны эвакуацияләү тәртибен эшләргә.

13. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы Премьер-министры А.В.ПЕСОШИН

Спорт

ak-bars.ru

Кубок аңа килешми

Дмитрий Квартальнов «Ак барс»тан китә. Дөресрәге, җибәрделәр. Казан клубы өч ел эшләгән баш тренеры белән килешүне озайтмаска булган. Сәбәбе билгеле. Димәк, «Ак барс» киләсе сезонга яңа остаз белән керәчәк. Кандидатлар арасында еш телгә алынган кеше – Зиннәтулла Билалетдинов.

Казан командасы быелгы плэй-оффның беренче өлешендә үк абынгач, Дмитрий Квартальновка төенчекләрен җыйнарга туры киләсен әле март башында ук фаразлый башладылар. Әмма баш тренерның язмышы турында рәсми хәбәр чыкканчы, төгәл бер ай вакыт узды. Нишләмәк кирәк, бер кат кисәнче җиде генә түгел, хәтта күбрәк итеп үлчи торган заманда яшибез. Хоккей ул кәшәкә һәм алка, кубок һәм очколар гына түгел, йөзләгән миллион сум чыгымнар да таләп итә.

Әле дә истә: моннан 3 ел элек Дмитрий Квартальновны журналистларга Түбән Камада тәкъдим иттеләр. ТАНЕКО заводына алып бардылар, башына эшче каскасы кигезделәр. Яңа баш тренер «үзебезнең егет» буларак танылырга тиеш иде. Дмитрий Квартальнов моны үзе дә тиз шәйләп алды. Эчендәгесе тышында булды, журналистлар белән ачык булырга тырышты, сүзгә саранлык күрсәтмәде. Нәтиҗәләре нинди генә булса да, үзенә карата беркемне дә битараф калдырмады.

Дмитрий Квартальнов Казанда «Ак барс» белән өч мәртәбә Гагарин Кубогын откан Зиннәтулла Билалетдинов урынын алды. Яңа тренерга үзен элеккеге остаз белән чагыштыруга түзәргә туры килде. Беренче сезонны ул уңышлы тәмамлады. Казан командасы даими чемпионатта Көнчыгыш конференциясендә беренче урынны алды. Плэй-оффта исә ахырга кадәр уйнау насыйп булмады: коронавирус аркасында Гагарин Кубогы өчен көрәшне туктатырга туры килде. Узган ел «Ак барс» Көнчыгыш конференциясе финалына кадәр барып җитте. Әмма 7 уенга сузылган сериядә «Авангард»ка оттырды. Омск командасының баш тренеры Боб Хартли хәйләкәррәк икәнен раслады. Быел көндәшләр янә плэй-оффта очрашты. Тик Дмитрий Квартальнов узган елгы җиңелүдән сабак алмаган булып чыкты. Аның үзе кебек туры бәреп, «дөбер-шатыр» уйнау рәвеше бу юлы да нәтиҗә бирмәде. Баш тренер тагын бер кат үзенең Кубок өчен көрәштә уңышсыз остаз булганын раслады.

Дмитрий Квартальновның уңышлары турында сөйләгәндә, күпләр аның яшь уенчылар белән эшли белгәнен искә ала. Моны ул Казанда да күрсәтте. Ул остаз булганда «Ак барс»та тәрбияләнгән 20 егет төп команда составында бозга чыкты. Барысы да уйнап китә алмады, әмма һөҗүмчеләр Артем Галимов, Дмитрий Воронков, Илья Сафонов һәм сакчы Даниил Журавлев бүгенге команданың аерылгысыз өлешенә әверелде. Тимур Билалов та нәкъ менә Квартальнов чорында төп капкачы булып өлгерде.

Икенче яктан карасаң, яшьләрне үстергән арада ул Зиннәтулла Билалетдиновтан калган команданы таркатып бетерде. Квартальнов чорында Казаннан Альберт Яруллин, Эмиль Гарипов, Джастин Азеведо, Станислав Галиев, Владимир Ткачев, Андрей Педан, Антон Ландер, Роб Клинкхаммер, Иржи Секач китеп барды. Алардан соң килгән Доус, Да Коста һәм башкалар да Казанда озак тоткарланмады. Квартальнов чемпион калган команданы таркатты, үзенекен исә җыя алмады. «Ак барс» составында хәзер дә яхшы уенчылар бар. Әмма зур җиңүгә барырлык команда булып укмаша алмадылар.

Квартальнов урынына кем килер? Кандидатлар арасында «Динамо» белән СКАны, соңрак Россия җыелма командасын җитәкләгән Олег Знарок, «Торпедо»да эшләгән, кайчандыр «Ак барс»та уйнаган Дэвид Немировски һәм үзебезнең Зиннәтулла Билалетдиновны телгә алалар. Күңелгә кайсының якынрак икәне аңлашыла инде. Әмма Зиннәтулла Билалетдиновның да Казаннан шул ук «Авангард»ка һәм шул ук Хартлига плэй-оффның беренче өлешендә 0:4 исәбе белән оттыргач киткәне искә төшә.

Марат ВӘЛИУЛЛИН,
«Ак барс»ның генераль менеджеры:
– Дмитрий Квартальнов белән хезмәттәшлегебез нәтиҗәле булды. Аны чакырып китерү стратегик максатларның бер өлешен үтәргә мөмкинлек бирде. Әмма без Кубок яулый алмадык, шуңа күрә тренерлар штабы белән килешүне озайтмау карары кабул ителде. «Ак барс»ның яңа баш тренеры 1 майга кадәр билгеләнәчәк.

Дмитрий КВАРТАЛЬНОВ:
– Мин клуб һәм республика җитәкчелегенә миңа ышаныч белдергәннәре һәм «Ак барс»та баш тренер булып эшләү тәҗрибәсе өчен рәхмәт әйтәм. Җанатарларга, хезмәткәрләргә, уенчыларга һәм иганәчеләргә даими ярдәм итүләре өчен рәхмәт. Кубок ота алмадык, әмма команданың моңа ирешү өчен зур мөмкинлеге бар. Мин Казанда бергә эшләгән хоккейчыларга ышанам һәм һәрберсенә уңышлар телим.

АЛСУ ХӨҖҖӘТОВА:
«МИН ҮЗЕМНЕ БАТЫРГА САНАМЫЙМ»

Менә шундый кеше

Азнакай районының Югары Стәрле авылында яшәүче 40 яшьлек Алсу Хөҗҗәтова 6 апрельдә 84 яшьлек әбине янгыннан коткара. Кызганыч, уттан котылса да, әби шул ук көнне кичке якта вафат була. «Бу хәсрәтне йөрәге күтәрә алмагандыр», – ди Алсу үзе. Без аның белән булган хәлләрне искә төшердек.

– 13 ел буе почтада хат ташучы булып эшләдем. Югары һәм Түбән Стәрле авылларында яшәүчеләргә хезмәт күрсәттем. Авыл җирлеге башлыгы социаль хезмәткәр эше бар дигәч, ике эшне бергә алып бардым әле башта. Әмма соңрак әби-бабайлар эше күңелемә якынрак икәнен аңладым да почтадан киттем. Ике эшем дә халык белән аралашу, аларга хезмәт күрсәтү иде, – дип сөйли Алсу.

Ул алты әби һәм бер абыйга хезмәт күрсәтә. Рәйсә Хәйдәрова йортында күңелсез хәл буласы көнне, күңеле сизепме, әби янына иртәрәк килә ул.

– Иртәнге сигезләр иде. Әбиемнең хәлләрен белешим дип килсәм, янгын хакында хәбәр бирүче җайланма кычкыра. Әллә нишләп киттем. Тизрәк өйгә ашыктым. Әбием, өйалдына чыгып, идәнгә яткан иде. «Нишләдең, Рәйсә апа?» – дим. Берни дәшми. Тизрәк өй эченә керергә ашыктым. Рәйсә апаның газы да сүнгән, плитәсе дә эшләми иде. Ут каян чыккандыр, белмим дә. Әмма өйнең икенче ягы яна иде, – ди ул.

Алсу тиз генә фельдшерны чакыра, аннары янгын сүндерүчеләргә хәбәр бирә. «Ирем белән икәү янган матрасны урамга алып чыгып сүндердек, идәннәргә су сиптек. Шөкер, йортны саклап калып булды. «Ашыгыч ярдәм» машинасы Рәйсә апаны хастаханәгә алып китте. 26 апрельдә туган көне дә иде әле аның. Тик кичке җидедә аның үлгәнен әйттеләр», – ди Алсу.

Рәйсә апа ике кыз, ике ул үстерә. Ананың йөрәге бу янгыннан да зуррак хәсрәтләрне күтәрә. Бер малае моннан 18 ел элек, икенчесе узган ел көз көне вафат була. Кече улының үлеменнән соң сулып, сулыгып кала. Алсу сөйләвенчә, Рәйсә апа еш кына зиратка уллары кабере янына бара торган була. Ике кызы Чаллы шәһәрендә яши икән. Алар әниләре янына еш кайтып йөри, шалтыратып хәлләрен белешеп тора.

tatarstan.ru

– Әле фаҗигагә кадәр бер кызы шалтыраткан иде аңа. Озак сөйләштеләр. Кызы 18 апрельдән ялга чыгасын әйтте. Әнисен үзләренә чакырды, бездә торып кайтырсың, диде. Рәйсә апа да, ярар, кызым, дигән иде. Насыйп булмаган, күрәсең. Рәйсә апаны югалтуны үзем дә авыр кичерәм. Елыйм да елыйм әле. Бик җайлы кеше иде. Беркайчан да каты бәрелмәде. Шулкадәр пөхтә иде. Кайчак, минем эшем юк, башкаларга бар, дип тә кире борыр иде. Әмма килүемне көтеп торды. Ашын пешереп, чәен куеп көтәр иде. Мин килгәч, аш аша, кызым, дип кыстарга яратты. Тик мин, эш урынында сыйланып йөрергә ярамый, дигәч, үзе утырып ашар иде. Мин ул арада аның вак-төяк эшләрем эшләдем, – дип искә ала Алсу.

Социаль хезмәткәрнең әлеге алымын җитәкчеләре дә бәяли. Шушы көннәрдә Казанга чакырып бүләклиләр үзен. Татарстанның хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира Зарипова рәхмәт хаты тапшыра.

– Минем урында бөтен кеше шулай эшләр иде. Үземне батырлык эшләгәнгә санамыйм. Бик читенсенәм дә инде. Бүләкләргә чакыргач та, бармыйм дигән идем. Әмма җитәкчем каршы килмәскә кушты. Мин үз эшемне башкардым, – ди ул. – Бу хәлдән соң мин өлкәннәргә тагын да игътибарлы булырга кирәк дигән уйга килдем. Алар бит бер җылы сүзгә, бергә утырып сөйләшүгә дә мохтаҗ. Картлык барыбызга да килә. Әнә шуны уйлыйм да нинди саваплы эшкә килеп эләккәнемне аңлыйм. Кеше рәхмәтләре безне тагын да бәхетле яшәтә.

Өлкәннәр генә түгел, һәр кеше үз йортына янгын хакында хәбәр бирүче җайланма куйдырсын иде, ди Алсу. Әгәр Рәйсә апаның өендә ул тавыш бирмәгән булса, өе дә янып бетәр иде, ди.

– Рәйсә апаның балалары кайтып йөрергә туган йортлары исән калды. Ут күршеләргә күчмәде. Әнә шуңа да сөенәбез. Әмма күңелдә яра бар. Рәйсә апаны югалту миңа бик авыр, – ди ул, күз яшьләрен сөртеп.

Сүз уңаеннан, Россиянең Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан буенча идарәсе матбугат бүлеге хәбәр иткәнчә, янгын хакында хәбәр бирүче җайланма 2016–2021 елларда 86 янгында 174 кешенең гомерен саклап калган. Алар арасында 66 бала да бар. 2022 елда янгынның ике очрагы теркәлеп, 3 кешене коткарганнар. Әлеге җайланманы Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов кушуы буенча урнаштыралар. Ул 70 яшьтән өлкәннәргә, Бөек Ватан сугышы ветераннарына, инвалидларга, күпбалалы гаиләләргә, социаль яктан имин булмаганнарга бушлай куела. 2016–2022 елларда шушы җайланманы куяр өчен бюджеттан 41 миллион 869 мең сум акча бирелгән. 114 мең йортта 348 мең җайланма урнаштырылган.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Лилия ГЫЙМАЗОВА

ҖАНЫМ ҖӘЛ ТҮГЕЛ СИҢА!

Безнең халык концертларга күчтәнәч белән йөрергә ярата. Чәчәк бәйләме – бер хәл, әле бит яраткан җырчыларына тере куян, әтәч, пар итекләр, ризык тулы пакет бүләк итүчеләр дә бар. Җырчыларның тамашачыдан тагын нинди сәер бүләкләр алганы бар икән?

Татарстанның атказанган артисты **Илсөя Бәдретдинова**га мондый сәер бүләкләрне концерт саен диярлек бирәләр.

– Нинди генә күчтәнәч белән килмиләр! Тере куяннар, әтәчләр, чебиләр алып килүчеләр булды. Аркамнан шап-шап итеп кагып: «Кызым, менә моны да ал әле», – дип, башларындагы яулыкшәлләренә хәтле бүләк итәләр. Беләзекләрен дә салып бирәләр кайчак. Берсендә олы гына яшьтәге бер әбекәй гомере буе кигән балдагын салды да: «Бабаң бүләк иткән балдак бу, кадерле кешемә бирер өчен саклаган идем», – дип, шуны бүләк итте. Соңгы арада тамашачым вазгыятьтән артта калмый: пакеты белән карабодай, шикәр, көндәлек кирәк-ярак, хәтта бәдрәф кәгазе дә менгерәләр. Дару бирүчеләр дә бар. Ә иң мөһиме – алар барысын да чын күңелләреннән бүләк итә. Концертка билет алып килгән икән, аның өстенә күчтәнәч тә бирү тиеш түгел үзе. Шулай да, бик матур күренеш бу, – ди Илсөя.

Яшь җырчылар **Алмаз Мирзаянов** белән **Зөлфирә Шәйдуллина**ның тәүге концертларында пар итекләр бүләк иткәннәр.

– Иң истә калган бүләк булды ул. Ул чакта бит бергәләп концерт куя башлаган гына идек. Арчадан Дилбәр ханым белән Хәлил абый бүләге иде алар. Әле дә, ел саен концертыбызга килеп, нәрсә белән булса да шаккатыралар! Елның нинди булуына карамастан, мин яраткан лалә чәчкәләрен алып киләләр. Шөкер, андый тамашачыларыбыз күп. Ә бер концертта кызык кына хәл булды. Кайда икәнен төгәл хәтерләмим, әллә ялгышып, әллә уенын-чынын бергә кушып, бер пакет ризык алып менделәр. Нәрсә генә юк иде анда… Хәтта чегы да! – дип сөйләде Зөлфирә.

Юмор остасы **Рамил Шәрәпов** та, тамашачылар сәер, кызыклы күчтәнәчләрне еш алып килә, ди:

– Берсендә сыерчык оясы бүләк иттеләр. Әһә, мин әйтәм, кайткач, берәр агачка элеп куясы булыр. Ачып карасам, ояның ишеге, ә эчендә күчтәнәчләре бар икән. Сыерчыклар, бер керсәләр, тиз генә чыга алмаслар иде ул оядан *(көлә)*. Аннан соң сәхнәгә сосискалар алып менгәннәре булды. Имеш, тазарып китмәм микән. Кырыну пәкесе (бритва) белән сабын бүләк итүче дә булды. Анысы кашларымны кырыр өчен. Шәрәпҗан образы тугач, ак майка бүләк итәргә тотындылар. Башмакларны әйтеп тә тормыйм инде – аларын бик еш бирәләр. Әле менә соңгы арада шикәр белән тоз менгерүчеләр дә бар. Актуаль бит!



Татарстанның халык артисты **Рөстәм Закиров** исә 1989 елда ук безнең газета – ул чактагы «Социалистик Татарстан» бүләк иткән радиоалгычны әле дә саклый.

– Бер бәйгедә җиңгән өчен бирделәр аны миңа. Ялгышмасам, «Россия-2» дип атала ул радиоалгыч. Елына күрә, бик заманча саналуын әле дә хәтерлим. Аннары «Җырлы Татарстан» бәйгесендә электр самавыры бүләк иткәннәр иде. Шулай ук бик истә калган. Тамашачыдан сәер бүләкләр алган булмады кебек. Гел кирәкле бүләкләр бирәләр иде миңа *(көлә)*. Элегрәк, кыш айлары салкын килгән чакта Әгерҗе якларында бәйләнгән оекбаш бүләк иткәннәре хәтердә. Пычаклар бирүчеләр дә булды. Ләкин минем өчен чәчәктән дә кадерле бүләк юк. Гомумән, әүвәлге елларда чәчәк бик дефицит нәрсә иде. Аны әллә кайлардан алып кайтып, саклап торып, концерт көнне тамаша залына кадәр алып килеп, бары тик бик хөрмәт иткән җырчыларына гына бирде тамашачы. Ә җырчы, үз чиратында, чәчкәләрне бик кадерле бүләк итеп кабул итте. Кызганыч, хәзер хәлләр башкачарак шул, – дип сөйләде ул.

Моннан ике еллап элек Татарстанның халык артисты **Гүзәл Уразова** Илсөя Бәдретдиновадан бик сәер, әмма бик кәттә бүләк алган иде. Сәхнәдә аңа, сарык бүләк итәм, дип вәгъдә биргән Илсөя Бәдретдинова сүзендә торды ул! Бу бүләктән соң ике ахирәтнең шалтыратып сөйләшкән видеоязмалары социаль челтәрләрдә шактый таралган иде. Тамашачылары исә җырчыга кул эшләнмәләре, пешкән ризыклар бүләк итәргә ярата икән.



– Бу концерт сезонында алган күчтәнәчләрнең иң истә калганнары – бәйләнгән оекбашлар һәм… пальто. Аны миңа Уфада яшәүче бер кыз бүләк иткән иде. Бик яратып киеп йөрим хәзер. Безнең йөзләр төшерелгән картиналар, балаларга төрледән-төрле уенчыклар, искитмәле чәчәк бәйләмнәре, ризыклардан – телеңне йотарлык бавырсаклар, каз, үрдәк, авыл йомыркасы… Бәлеш пешереп алып килгән тамашачылар да шактый күп булды. Күчтәнәчләрдән өзмиләр диярлек, әмма безнең өчен иң кадерлесе – үзләренең зурлап килүе, – ди Гүзәл.

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 7066 данә
Гомуми тираж – 16091 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 252

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+